ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д.52, с.Старое Чурилино, Арский
муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арча
муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«06» май 2022 ел** **№ 16**

«2022 – 2024 елларга «Иске Чуриле»
муниципаль берәмлегендә кече һәм урта
эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль максатчан
программасы турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнары нигезендә Иске Чуриле башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Бирелгән «2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чуриле» муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль программасын расларга.

2. Чараларны башкаручыларга «2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чуриле» муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында бастырырга.

4. Әлеге карар аны бастырып чыгарган көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Иске Чуриле авыл җирлеге башлыгы Р.Т. Һидиятуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН1609012614

**РАСЛАНДЫ**
Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чуриле башкарма комитетының 2022 елның «06» май 16 нчы номерлы карары белән

**«2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чуриле» муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль максатчан программасы**

Гомуми нигезләмәләр

Программаның төп максаты булып «2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чуриле» муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм күрсәтү һәм әлеге нигездә халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм мәшгульлеген үстерү, җитештерү, акыл һәм интеллектуаль потенциалны үстерү тора.

Муниципаль программаның паспорты

| | |
|---|---|
| 1. Муниципаль программаның исеме | «2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чуриле» муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль максатчан программасы |
| 2. Муниципаль программаны эшләү өчен нигез | «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законнары; «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы |
| 3. Муниципаль программаның | Иске Чуриле башкарма комитеты |

| | |
|---|---|
| муниципаль заказчысы | |
| 4. Муниципаль программаның төп максаты | - кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен уңай мохит тудыру;<br><br>- эшләп килүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын саклауга һәм яңаларын булдыруга ярдәм күрсәтү;<br><br>- базарны җирле җитештерүчеләр товарлары һәм хезмәтләре белән тулыландыру;<br><br>-авыл җирлеге халкының мәшгульлеген тәэмин итү. |
| 5. Муниципаль программаның төп бурычлары | - барлык дәрәҗәдә дә бизнес һәм хакимият хезмәттәшлеген тәэмин итү, җирле үзидарә органнары, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары (алга таба – Субъектлар) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларның (алга таба – Оешмалар) үзара хезмәттәшлек төрләрен һәм механизмнарын үстерү һәм камилләштерү;<br><br>- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү мониторингы;<br><br>- җәмәгатьчелектә кече һәм урта эшмәкәрлеккә карата уңай караш тудыру;<br><br>- җитештергән товарларын (эш, хезмәт күрсәтү) җәелдерүдә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү. |
| 6. Муниципаль программаның төп чараларын башкаручылар | Иске Чуриле башкарма комитеты |
| 7. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | 2022-2024 еллар |
| 8. Муниципаль программаның максатына | - кече эшмәкәрлек субъектлары |

| | |
|---|---|
| ирешү индикаторлары | санын арттыру;<br><br>- өстәмә эш урыннары булдыру һәм кече бизнес белән шөгыльләнүчеләр санын арттыру;<br><br>- җитештерү күләмен арттыру, продукцияне сату базарын киңәйтү;<br><br>- җирлек территориясендә җитештерелә торган товар төрләрен арттыру. |
| 9. Муниципаль программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Җирле үзидарә органнарын агымдагы финанслау |

## 1 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫҢ ПРОБЛЕМАСЫ ҺӘМ МАКСАТЫ

Кече эшмәкәрлек – икътисад һәм сәяси тотрыклылык, иҗтимагый үсеш, товарларның яңа төрләрен үзләштерү, хезмәт күрсәтүне үстерүдә мөһим роль уйнаучы икътисадның өстенлекле секторы. 2022 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чуриле» муниципаль берәмлегендә 6 кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты үз эшен алып бара.

## 2 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ВАКЫТЫ

Программаны гамәлгә ашыру вакыты – 2022 елдан 2024 елга кадәр

## 3 бүлек. ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫНЫҢ ИСЕМЛЕГЕ ҺӘМ ТАСВИРЛАМАСЫ

| № | Чараның исеме | Башкару вакыты | Чараларны башкаручылар | Финанслау күләме (еллап) җирле бюджет хисабына | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1 ел | 2 ел | 3 ел | Барлыгы |
| Муниципаль программаның максаты | | | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.1.Төп чаралар:<br><br>- товар сату, эш, хезмәт күрсәтү базарын үстерү максатында җирлектәге кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын күргәзмә һәм ярминкәләрдә катнашуга тарту; | 2022-2024 еллар | Иске Чуриле башкарма комитеты | Агымдагы финаслау | Агымдагы финаслау | Агымдагы финаслау | Агымдагы финаслау |
| 1.2.Төп чаралар:<br><br>- җирлектәге кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен дәүләт ярдәме алу буенча консультацияләр үткәрү. | 2022-2024 еллар | Иске Чуриле башкарма комитеты | Агымдагы финаслау | Агымдагы финаслау | Агымдагы финаслау | Агымдагы финаслау |

## 4 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЫНА ИРЕШҮ ИНДИКАТОРЛАРЫ

| Индикатор исеме | Үлчәү берәмлеге | 2018 базаелан дагы күрсәткеч | Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның 1 елы | Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның 2 елы | Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның 3 елы |
|---|---|---|---|---|---|
| - кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары санын арттыру | билгеләнгән тәртиптә теркәлгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны | 6 | 1 | 2 | 3 |
| - өстәмә эш урыннары булдыру һәм кече бизнес белән шөгыльләнүчелә | кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан булдырылган эш урыннары саны | 6 | 1 | 2 | 3 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| р санын арттыру; | | | | | |
| - җирлек территориясендә җитештерелгән товар төрләрен арттыру. | кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары җитештергән товар төрләре саны | 6 | 1 | 2 | 3 |

## 5 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ӨЧЕН КИРӘК БУЛГАН РЕСУРСЛАР

| Финанслау чыганаклары | Еллар | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Муниципаль программаны тормышка ашыруның 1 елы | Муниципаль программаны тормышка ашыруның 2 елы | Муниципаль программаны тормышка ашыруның 3 елы | Муниципаль программаны гамәлгә ашыру чорында барлыгы |
| Җирле бюджет | Агымдагы финаслау | Агымдагы финаслау | Агымдагы финаслау | Агымдагы финаслау |

Программаны финанслау чаралары авыл җирлеге бюджеты хисабына башкарыла.

Бюджет чаралары күләме фараз характерында билгеләнә һәм ел саен билгеләнгән тәртиптә чираттагы бюджет проектларын төзегәндә исәпкә алына.